**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЕВЯТЕРНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕВӘТЕРНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2025 Девәтернә авылы № 2

2025 елга вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 23.01.2025 елның 33 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны (ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2025 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны (ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2025 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәлләре 01.02.2025 елдан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Э.Э. Ганиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Девәтернә авыл
җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2025
елның 2 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны (ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2025 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Т/с** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3924,92 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 963,31 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4277,14 |
| | **Барлыгы** | **9165,37** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Девәтернә авыл
җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2025
елның 2 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны (ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2025 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Т/с** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Тәнне төрү | 705,94 |
| 3. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3537,31 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 867,75 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4054,37 |
| | **Барлыгы** | **9165,37** |